Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

КАРАР № 2

Шумково авылы 2024 елның 5 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручының 2023 елга хисабы һәм җирлек Советының 2024 елга бурычлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсендәге 5, 5.1 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсендәге 7, 7.1 өлешләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Р. Гыйләҗиеваның 2023 елга хисабын һәм җирлек Советының 2024 елга бурычлары турында чыгышын игътибарга алырга, эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге җирле үзидарә органнары алдына 2024 елга гражданнарның үзара салым акчалары хисабына башкарырга түбәндәге бурычларны куярга:

- Хутор авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, тигезләү, юлларны кардан чистарту);
- авыл җирлеге территориясен җәйге чорда чүп-үләннәрдән арындыру (чабу) (шартнамә буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Олы Укмас авылында зиратны киртәләп алу өчен материал сатып алу;
- территорияне төзекләндерү (уңайлылык булдыру) (Олы Укмас авылында чүплекне рекультивацияләү);
- Олы Укмас авылында юлны ремонтлау һәм карап тору (тоту) (зиратка юл өчен вак таш сатып алу, тигезләү, юлны кардан чистарту);
- Шумково авылында урамны яктырту челтәрләрен карап тору (тоту) (светодиодлы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- авыл җирлеге чикләрендәге юлларны кышкы чорда карап тоту (юлларны кышкы чорда кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- евроконтейнерлар сатып алу;
- суэтем насосы сатып алу;
- территорияне төзекләндерү (Шумково авылында чүплекне рекультивацияләү);
- авыл җирлеге территориясен җәйге чорда чүп-үләннәрдән арындыру (чабу) (шартнамә буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4. Шумково авыл җирлеге Башкарма комитетының гражданнардан кергән хатлар, гаризалар, шикаятьләр белән эшен катгый контрольдә тотарга.

5. Әлеге карарны Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус стендларында:

Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урам, 4 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьлек урамы, 5 йорт; Әшнәк-Качкалак авылы, Югарыгы урам, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Н.П Власов